КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2024 ел, 2 октябрь

г.Казань

№ 852

2024 елда 2023 елда үткәрелгән «Коммерциягә карамаган оешманың һәм гавами хакимият органының иң яхшы архивы - Татарстан Республикасының дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагы» республика конкурсында җиңүче буларак «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесенә акчалата бүләкләү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансферт бирү кагыйдәләрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2024 елда 2023 елда үткәрелгән «Коммерциягә карамаган оешманың һәм гавами хакимият органының иң яхшы архивы - Татарстан Республикасының дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагы» республика конкурсында җиңүче буларак «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесенә акчалата бүләкләү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансферт бирү кагыйдәләрен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 2 октябрь, 852 нче карары белән расланды

2024 елда 2023 елда үткәрелгән «Коммерциячел булмаган оешманың һәм гавами хакимият органының иң яхшы архивы - Татарстан Республикасының дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагы» республика конкурсында җиңүче буларак «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесенә акчалата бүләкләү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансферт бирү кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр 2024 елда 2023 елда үткәрелгән «Коммерциячел булмаган оешманың һәм гавами хакимият органының иң яхшы архивы - Татарстан Республикасының дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагы» республика конкурсында җиңүче буларак «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесенә акчалата бүләкләү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансферт бирү механизмын билгели (алга таба тиешенчә - бюджетара трансфертлар, «ТР ТММИФ» ДУ, Конкурс).

2. Әлеге Кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты (алга таба – ТР Архив буенча дәүләт комитеты).

3. Бюджетара трансферт тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Кагыйдәләрнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга ТР Архив буенча дәүләт комитетына билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциячел булмаган оешманың һәм халык хакимияте органы – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» һәм «Коммерциячел оешманың – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурслары турында» 2018 ел, 01 октябрь, 889 нчы карары белән расланган «Коммерциячел булмаган оешманың һәм халык хакимияте органы – Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) архивын комплектлау чыганагының иң яхшы архивы» республика конкурсы турында нигезләмәнең (алга таба - нигезләмә) 2.6 пунктында каралган нәтиҗәләргә ирешү максатларында Конкурс җиңүчесе буларак «ТР ТММИФ» ДУга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан бюджетара трансферт чараларын бирү.

Конкурста җиңүче буларак «ТР ТММИФ» ДУ Нигезләмәнең 2.6 пунктында каралган нәтиҗәләргә ирешүне, Нигезләмәнең 2.4 пунктында билгеләнгән чыгымнар юнәлешләре нигезендә тәэмин итә.

5. Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бирелә торган бюджетара трансферт күләме - 1 000 000 сум.

6. Бюджет акчаларын баш бүлүче буларак «ТР ТММИФ» ДУ һәм аның вазыйфаи затлары тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган өчен законнар нигезендә җаваплы булалар.

7. Бюджет акчаларын баш бүлүче буларак «ТР ТММИФ» ДУ тарафыннан бюджетара трансфертларны максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акчалар суммасын тулы күләмдә бәхәссез түләтүгә китерә.

8. Бюджет акчаларын баш бүлүче буларак «ТР ТММИФ» ДУ дәүләт бюджет трансфертын алу өчен ТР Архив буенча дәүләт комитетына түбәндәге документларны тапшыра:

ТР Архив буенча дәүләт комитетына боерыгы белән расланган форма буенча бюджетара трансферт бирү турында гариза;

бюджетара трансфертлар бирү турында гаризага кул куйган затның вәкаләтләрен раслый торган документ.

9. Бюджет акчаларын баш бүлүче буларак «ТР ТММИФ» ДУ тарафыннан кергән документлар ТР Архив буенча дәүләт комитеты тарафыннан, алар кергән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә карала. Документларны карау йомгаклары буенча ТР Архив буенча дәүләт комитеты бюджетара трансферт бирү турында яисә бюджетара трансферт бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә.

10. Бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Кагыйдәләрнең 8 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

әлеге Кагыйдәләрнең 8 пунктында күрсәтелгән документлардагы мәгълүмат дөрес булмау.

11. Әлеге Кагыйдәләрнең 4 пунктында күрсәтелгән бюджетара трансферт бирү нәтиҗәләренә 2024 елның 25 декабренә кадәр ирешелергә тиеш.

Бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешү турында хисап һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы бюджетара трансферт булган чыгымнар турында хисап бюджет акчаларын баш бүлүче буларак «ТР ТММИФ» ДУ тарафыннан ТР Архив буенча дәүләт комитетына Р Архив буенча дәүләт комитеты раслаган формалар буенча кәгазь чыганакта 2025 елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

12. Бюджетара трансферт ТР Архив буенча дәүләт комитетының тиешле таләбе алынган көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

бюджетара трансфертны максатчан файдаланмаганда;

бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешмәгәндә.

13. ТР Архив буенча дәүләт комитеты бюджетара трансферт бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетының Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсендә ачылган бердәм счетына бюджетара трансферт күчерә.

14. 2025 елның 1 гыйнварына карата файдаланылмаган бюджетара трансферт акчасы 2025 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты keremenә кире кайтарылырга тиеш.

15. Бюджетара трансфертның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемена күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемена түләтелергә тиеш.

16. Бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Архив буенча дәүләт комитеты  тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---